## «Бүгенге киенү модасында юморга урын бар»

Руфинә фикеренчә, стиль ул хәтта булачак тормышыңны да хәл итә торган мөһим фактор. Мәсәлән, кияүгә чыгарга теләгән кызларга ул «романтик» стильне сайларга киңәш итә. Матур күлмәк, билдә «утырган» купшы итәккә ир-атларның барысы да игътибар итәчәк, ди ул.

6 БИТ

## Компьютер белән бер телдә

Чаллы егете Марат Исмәгыйлов – «IT-Планета 2016/17» инновацион технологияләр өлкәсендә барган халыкара олимпиада финалисты. Яшь белгеч дөньяның 12 иленнән килгән 17 мең катнашучы арасында иң көчле программистларның берсе булып танылды.

3 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

# Шәһри КАЗАН

татмедиа

**Җомга** | 2.06.2017 | № 59 (5821)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

## Ленар Сафин:

# «БЕЗ ТЫЛСЫМЧЫЛАР ТҮГЕЛ ШУЛ»

ЮЛ ТӨЗЕЛЕШЕ

Автор фотосы

**Татарстанның транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Ленар Сафин Министрлар Кабинетында узган брифингта казанлыларның бер-ике атнага сабыр итүләрен сорады.**

**Дамир БӘДРИЕВ**

– Конфедерация Кубогы матчларына әзерлек кысаларында, Казанда 26 урам юлы төзекләндерелә. Һава торышы бераз комачаулый. Юл төзүчеләр тылсымчылар түгел, ләкин эшне футбол матчларына кадәр өлгертәчәкбез. Юл төзелешләре барганда, хәрәкәт кыенрак, әлбәттә. Яхшы юллар барлыкка киләчәк, шунлыктан аз гына сабыр итик, – диде министр Ленар Сафин.

Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – тышкы төзекләндерү комитеты рәисе Игорь Куляжев өстәп әйткәнчә, башкалада гомуми исемлектә 64 урам юлы һәм 95 ишегалды юлы төзекләндерелә.

– Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тәләктәшлегендә, Казанда 2011 елдан башлап инде 1445 ишегалды яңартылды, – диде Игорь Куляжев.

Бу әле шәһәрдәге ишегалларының 48 проценты гына.

Ленар Сафин сөйләгәнчә, Казан белән Чаллы агломерацияләре «Имин һәм сыйфатлы юллар» федераль өстенлекле проектына кертелгән. Агломерация шәһәрнең эчке юлларын һәм федераль автотрассаларның шәһәргә тоташкан өлешләрен колачлый. Федераль һәм республика бюджетлары хисабына бүлеп, тулаем исәптә, Казанда – 120, ә Чаллыда 62,7 километр юл төзекләндерелә.

Республикада бу җәйдә федераль һәм төбәк әһәмиятендәге 120 километр яңа юл төзү, гамәлдәге юлларның 1200 километр өлешенә капиталь ремонт үткәрү каралган. Биш яңа күпер салыначак.

– Татарстан Президенты муниципаль берәмлекләрдә юллар төзү мәсьәләсенә нык игътибар бирә, – дип дәвам итте сүзен министр Ленар Сафин. – Быел 27 торак пунктка асфальт юл сузыла. Гомумән, 2010 елдан бирле 372 авыл асфальт юллар белән тоташтырылды. Авылларда 370 урам юлы яңартыла.

Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге федераль автомобиль юллары идарәсе җитәкчесе Илдар Минһаҗев, М-7 «Волга» федераль автотрассасының Казан белән Чаллы арасындагы өлешен үзгәртеп төзү 2018 елга тәмамланачак, дип ышандырды.

– Питрәч районындагы Шәле авылыннан Балык Бистәсенең Күки авылына кадәрге өлештә ике участок былел файдалануга тапшырыла. Киләсе елда тагын бер 31 километрлы участок эшләнеп бетәчәк. Юл аварияләрендә һәлак булганнарга федераль автотрасса читендә кабер чардуганнары куелырга тиеш түгел, әлбәттә. Юл читләрендәге чардуганнар алынырмы яки калдырылырмы, бу хакта әле тәгаен бер карар юк, – диде Илдар Минһаҗев.

Юл төзелешендә сыйфат – катгый таләп, дип искәртте министр Ленар Сафин. Казанда, мәсәлән, подрядчы оешма, узган ел Әмирхан урамы юлына асфальт түшәгәндә тиешле таләпләрне саклмаганы өчен, быел шул ук эшне үз хисабына кабат башкарырга мәҗбүр булган.

# Фаразлау алты көнгә китсә – ышанма

АЛЛА САКЛАСЫН!

vk.com

**Мәскәүдә быелның 29 маендагы җилдавылда 16 кешенең гомере өзелде, 170 кеше төрле авырлыкта имгәнү алды. Әлеге гарасат Мәскәүдә 1904 елдагы җил-давылга тиң булган.**

– Татарстанда Мәскәүдәге кебек көчле гарасатлар көтелми, – дип өметләндерде республиканың Гидрометеорология үзәге җитәкчесе Феликс Гоголь кичә «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Әмма дә ләкин республикада мессенджер, ягъни тиз мәгълүмат алмашу программасы нигезендә, халыкка «Татарстанда Мәскәүдәгедән дә җимергечрәк гарасат булачак» дигән хәбәр таратылган.

– «Билайн» үзенең клиентларына – өч миллион, «Мегафон» 230 меңнән артык SMS җибәргән, МТС та калышмаган. Элемтә операторларының «коткы тарату» гамәле тикшерелә, – диде Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең «Кризислы очраклардагы идарә үзәге» җитәкчесе Радик Гыйсмәтов.

**МЧСтан КИҢӘШЛӘР**

***Гарасат вакытында агач яки реклама корылмасы астында басып тормагыз, ышанычлы бина эченә керегез; тәрәзәләрне ябыгыз; эчәргә яраклы су запасы туплап куегыз; җил-давыл башланганда, урамга чыкмагыз, ачык һавада калсагыз, чокырга төшеп яки җиргә сузылып ятыгыз; балконнарны төрле әйберләр белән тутырмагыз; җил-давыл башланачагы турындагы хәбәрне туганнарыгызга һәм башкаларга хәбәр итегез.***

Татарстан Гидрометеорология үзәге яки МЧС тарафыннан рәсми рәвештә таратылган мәгълүматка гына нигезләнергә кирәк.

– Кайбер массакүләм мәгълүмат чаралары әллә нинди чыганакларга таянып, ун көнгә һәм аннан да күбрәк вакытка һава торышын бирә. Имеш, унынчы көндә – яңгыр. Бу һич тә дөрес түгел. Һава торышын – өч, әиң күбе биш көнгә фаразларга була, – дип кистереп әйтте Феликс Гоголь.

Димәк, алтынчы көнгә нәрсә буласын бер Ходай гына белә.

– Климат үзгәреш кичерә – монысы хак. Егерменче гасырдан башлап, Җир йөзендә температура акрынлап күтәрелә бара. Бу үзгәрешләр Татарстанга да тәэсир итәчәк. Туфрактагы һәм һавадагы корылыклар, җил-давыллар куәтләнәчәк. Климат үзгәрешенә төзелеш, энергетика, авыл хуҗалыгы тармакларының алдан ук әзерлек күрүләре зарур, – дип искәртте Феликс Гоголь.

Татарстан Гидрометеорология үзәге мәгълүматларына караганда, 3 июньдә 9-14 градус җылылык көтелә.

– Якшәмбедә, ягъни 4 июньдә тагын суыта: көндез – 4-9 градус,ә төнлә 3-8 градус кына җылы булачак. Яңгыр, урыны белән боз явачак, секундына 20 метр тизлектә җил исәчәк, – дип, үзләренең фаразлары белән уртаклашты Феликс Гоголь.

– Җил секундына 20 метр тизлектә искәндә, корыган агачлар, реклама конструкцияләре аварга мөмкин, – дип өстәде Радик Гыйсмәтов.

**Дамир БӘДРИЕВ.**

## Гарасат

**Җәйнең беренче көне республикада көчле давыл һәм гарасат белән башланды. Тотрыксыз һава торышыннан аеруча да Татарстанның көньяк һәм көнчыгыш районнары – Аксубай, Актаныш, Әлмәт, Зәй, Нурлат, Чирмешән зыян күргән.**

Нурлатта давыл каты дуламаган.

– Башка районнар белән чагыштырганда, бездә давыл көчле булмады, өермә күренмәде. Ләкин кисәк көчле җил чыкты, боз ява башлады. Ярый әле түбәләр купмады. Сәгать бишкә кадәр күк күкрәп торды, яшен яшьнәде. Давыл аркасында, ярты сәгатькә ут сүнгән иде, балалар куркып бетте, – ди Нурлат шәһәрендә яшәүче Лилия Михеева.

Ә көндезге өченче яртылар тирәсендә көньяк-көнбатыштан килгән җил-давыл, дөресрәге, өермә Чирмешәннең Югары Чыктай һәм Түбән Чыктай авылындагы йортларның түбәсен кубарган, абзар, каралты-кураларны җимергән, агачларны аударган, электр, газ үткәргечләрне өзгән. Карлы боз яуган. Гарасат аеруча да Югары Чыктайда да котырган. Монда башлангыч мәктәп бинасына зыян килгән. Җил мәчет түбәләренең калайларын куптарган. Аннан соң да әле районда озаклап көчле яңгыр яуган.

– Өермәне мин үзем күрмәдем, ул вакытта өйдән 50 чакрым ераклыкта идем. Хатыным аны фотога төшереп алган да миңа җибәрде. Өермә якынча ун минут тирәсе дулаган. Ярый әле Чирмешәннең үзен читләтеп үтте. Ә минем күрше авыллар бик нык зыян күрде. Чирмешәннән биш минутлык юл аерып торган авыл бомба төшкән кебек калган, – ди Павел Фомин.

Татарстанның төрле районнарында төшерелгән өермә фотосы социаль челтәрләрдә таралса да, республиканың гидрометеорологик үзәге андый хәл булмады ди. Кемгә ышанырга?

# Роботлар ит, балык эшкәртә

**Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы, югары технологияләр ярдәмендә, 2025 елга авыл хуҗалыгы җитештерүчәнлеген 25 процентка арттырып булачак, дип саный. Бу хакта «Известия» басмасы хәбәр итә.**

– Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгында 2025 елга федераль фәнни-техник программа эшләнде. Аны тормышка ашырганда, без авыл хуҗалыгы предприятиеләре белән фәнни оешмалар лицензияле килешүен 50 процентка арттырырга ниятлибез. Бу исә 2025 елга авыл хуҗалыгы җитештерүчәнлеген 25 процентка арттырырга мөмкинлек бирәчәк, – дип билгеләп үтә Россия авыл хуҗалыгы министры Александр Ткачев Петербург халыкара икътисади форумы трибунасыннан.

Ткачев сүзләренчә, хәзердән үк Россия авыл хуҗалыгын югары технологияле инновацион тармак буларак әйтеп үтәргә була: роботлар ит, балык эшкәртә, «акыллы» машиналар үсемлекләрне сканерлый һәм чүпләрне юк итә, ә пилотсызлар чәчүлекләрне контрольдә тота һәм уңышны фаразлый.

Россия Авыл хуҗалыгы министрлыгы башлыгы инновацияләрне гамәлгә кертү нәтиҗәләренең үстерүдә, үзкыйммәтне киметүдә, әйләнә-тирә мохиткә начар тәэсирне бетерүдә ярдәм итәчәгенә ышаныч белдерә. Аның сүзләренчә, соңгы ун елда Россиядә бөртеклеләрдән уңыш 40 процент чамасы үскән, ә азыкны конверсияләү, мәсәлән, дуңгызчылыкта, киресенчә – 1,5 тапкырга кимегән.

# Башкортстанда Тукайны искә алдылар

Уфа шәһәренең иҗат әһелләре Тукайның Уфага килүенә 105 ел тулуны билгеләп үтте, дип хәбәр итә «Татар-информ».

Төбәкнең «Башкортстандагы татар милли-мәдәни автономиясе» республика башлыгы хакимияте, Халыклар дуслыгы йорты ярдәмендә, «Тугандаш халыклар әдәбиятында буыннар кабул итүе» II Бөтенроссия конференциясен уздырды. Әдәби симпозиум Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетында үтте.

– Казан, Оренбург, Чиләбе галимнәре бүген бөек шагыйрьнең безнең халык әдәбиятында тоткан урынын искә алды, «Тукай әдәбиятта» энциклопедиясен презентацияләде. Башкорт дәүләт педагогия университеты доценты Альбина Хәлиуллина китабы зур кызыксыну тудырды, ул татар һәм башкорт шагыйрьләренең Тукай турындагы шигырьләреннән җыентык эшләгән», – дип сөйли Башкортстандагы татар милли-мәдәни автономия җитәкчесе Римма Утяшева. Ул шулай ук Уфада Габдулла Тукайга һәйкәл куелырдиган өметтә торуларын белдерә.

# Компьютер белән бер телдә

**Чаллы егете Марат Исмәгыйлов – «IT-Планета 2016/17» инновацион технологияләр өлкәсендә барган халыкара олимпиада финалисты. Яшь белгеч дөньяның 12 иленнән килгән 17 мең катнашучы арасында иң көчле программистларның берсе булып танылды.**

Алисә САБИРОВА

vk.com

«IT-Планета» олимпиадасы – программистлар арасында иң дәрәҗәле ярышларның берсе. Аны «Intel», «1С», «Huawei», «IntelSystems» кебек халыкара оешмалар үткәрә. Сайлап алу турларында ярышта Татарстаннан 598 IT-белгеч катнашкан. Шуларның нибары алтысы гына финалга чыкты. Марат – финалистларның берсе.

Егет Тимерясов исемендәге Казан инновация институтының Чаллы филиалында IV курста белем ала. Шул ук вакытта ул шәһәрнең IT-паркында эшли. Марат узган ел да үз көчен әлеге олимпиадада сынап караган инде.

– Мин олимпиаданың 3D модельләштерү юнәлешендә катнаштым. Безгә китап өчен компьютерда 3D рәсемен ясарга кушылды. Гомумән, бу көндәлек тормышта бик таралган өлкә. Инженерлар 3D модельләштерү ысулы белән машина двигательләре ясый, дизайнерлар өй, бүлмә интерьерын төзи. Хәтта сез яратып караган мультфильмнарны да программистлар эшли. Миңа кибер-төзелеш ошыйрак төшә. Компьютер уеннары ясау бер яктан – сәнгать, икенче яктан – бик яхшы бизнес, – ди Марат.

Аның әйтүенә караганда, компьютер уеннары төзүчеләр даими рәвештә 60-100 мең сум хезмәт хакы ала икән.

Быел егет университетта соңгы елын укый. Диплом алуга армия хезмәтенә китмәкче. Киләчәктә үзен яхшы IT-белгеч буларак күрә ул.

# Ришвәтчелекнең «вирусы» зәхмәтле

vk.com

**«Коррупция «вирусы» белән өлкәдәге структура вәкилләре генә түгел, ә бизнес өлкәсе дә зарарланган. Безнең бурыч – мөмкин булган барлык ысулларны кулланып, коррупциягә каршы көрәшү.»**

Дамир БӘДРИЕВ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанда 31 майда «Коррупциягә каршы стандартлар булдыру һәм аларны куллану мәсьәләләре» буенча Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясендә катнашучыларга мөрәҗәгать итеп әйтте бу сүзләрне.

– Хәзерге заман шартларында икътисадны, көндәшлекне үстерү, инновацияле проектларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, шулай ук инновацияле сәнәгатькә йөз тотып эшләү актуаль, – диде Рөстәм Миңнеханов конференциянең пленар утырышында. – Әмма коррупциянең таралу зурлыгын исәпкә алсак, бу күренеш белән көрәшү өчен өстәмә ысуллар кулланырга кирәк.

Президент коррупциягә каршы көрәштә катгый ысуллар куллану зарурлыгын искәртте.

– Татарстанда бу эш инде башланды, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Коррупциягә каршы сәясәткә нигезләнеп, республиканың эре компанияләре стандартлар кабул итте. Югары технологияле җитештерүне үстерү, инвестицияләр җәлеп итү – эшчәнлегебезнең өстенлекле юнәлешләренең берсе. Без көндәшлеккә сәләтле, дәүләткә файда китерә, халыкка уңайлы тормыш бирә торган нәтиҗәле икътисад төзергә омтылабыз.

Ил күләмендә куркыныч янаган коррупция шартларында бу бурычны үтәү мөмкин түгелләнгән басым ясап әйтте ул.

– Мәсьәләнең гаять мөһимлеген аңлаганга, Татарстан 2005 елда ук коррупциягә каршы көрәш стратегиясен булдырды һәм аны гамәлгә ашыра, –диде Рөстәм Миңнеханов. – Стратегиянең төп юнәлешләре дип дәүләт идарәсен үтә күренмәле итүне, күпчелек дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне стандартлаштыруны, дәүләт органнары эшчәнлеген контрольдә тотуга җәмәгатьчелекне җәлеп итүне әйтергә мөмкин.

Президент бу мәсьәләдә «Ачык Татарстан» порталының нәтиҗәле эшчәнлек алып баруын билгеләп үтте.

Конференциядә Россия Федерациясендә коррупциягә каршы стандартлар җыелмасы турында фикер алышу булды. Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО) стандартлары, шулай ук коррупциягә каршы халыкара стандартлар исәпкә алынды. Мәсәлән, стандартлар буенча, дәүләт һәм муниципаль органнар хезмәткәрләренә чит ил банкларында акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, хисап ачу, кыйммәтле кәгазьләр белән эш йөртү, вазифадан файдаланып, бүләкләр алу һәм бушлай төрле хезмәтләрдән файдалану, эшкуарлык белән шөгыльләнү тыела.

**Җәйге еллар чорында күпләр чит илләргә юл ала. Араларында туристлык агентлыкларыннан юллама алучылар да күп. Белгечләр фикеренчә, җәйге сезонда бер көнлек туристлык фирмаларыннан зыян күрүчеләрнең саны арта. Роспотребнадзор идарәсенең кулланучылар хокукларын яклау бүлеге җитәкчесе Ирина Әхмәтшина бу уңайдан республика халкын сак булырга чакыра.**

## Чит илгә барырга уйласаң

– Юллама алганда, туристлык агентлыгының туроператор белән төзегән килешүен сорарга кирәк. Чынлап та аларның туристлык продуктын сатамы-юкмы икәнлеге белән кызыксыныгыз. Туристлык агентлыгында сезгә бару-кайту, яшәү, туклану шартлары турында бәйнә-бәйнә сөйләргә тиешләр. Турагент вәгъдә иткән хезмәтләр килешүдә чагылырга тиеш. Соңгы ике елда бертөслерәк мөрәҗәгатьләр кабул ителде. Әйтик, бер оешма турпродукт урынына алдан урын броньлау турындагы килешүне тәкъдим иткән. Кулланучылар килешүне яхшылап укып карагач, анда юл, ашау кебек пунктларның булмавын ачыклаганнар. Аларның акчаларын кире алганда, проблемалар килеп туды. Кайбер очракта биш йолдызлы кунакханә урынына түбәнрәк категориялесенә урнаштырып куярга яки диңгезгә унбиш минутлык юл дигәне бер сәгатьлек булырга мөмкин. Көтеп алган ялыгыз кәефегезне бозмасын өчен, килешү төзегәндә игътибарлы булыгыз, – дип сөйләде ул «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

«Казан» аэропортының Татарстан таможнясы посты башлыгы Мирзанур Гәраев сүзләренчә, соңгы биш айда, узган елгы шушы чор белән чагыштырганда, халыкара рейслар саны 80 процента арткан. Аның каравы, таможня аша чыкканда кагыйдә бозуларның саны да ике тапкырга арткан. Административ хокук бозуларга килгәндә, алкоголь эчемлекләр, тәмәке, салкын корал, Кызыл китапка кертелгән төрле хайваннар сөяте (чучело), экстремистик әдәбият алып керүләр ешайган. Мирзанур Гәраев товарларның авырлыгы 50 кг нан арткан яки аларның бәясе ун мең евро булган очракта, таможня декларациясен тутырырга кирәклеген дә искәртте. Аны Федераль таможня хезмәте сайтында шәхси кабинет булдырып, электрон форматта да тутырып була, диде ул.

Роспотребнадзор идарәсенең санитар сак территориясе буенча бүлек җитәкчесе Луиза Борисова да үзенең чыгышында, үткән ел белән чагыштырып караганда, чит илдән инфекцион авырулар алып керү куркынычының артуын билгеләп үтте.

– Конго, Ангола, Йәмәндә инфекцияләр, аерым алганда, Эбола вирусы һәм холера таралган вакыт. Кытайда исә кош гриппы йоктыруның яңа очраклары билгеле булды. Әлеге илләргә барганда сак булырга кирәк, – дип кисәтте спикер.

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.**

КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

# Куллана белсәң – дару, белмәсәң – агу

**Бүгенге заманда интернетсыз тормышны күз алдына да китереп булмый. Куллана белсәң – дару, белмәсәң – агу, диләрме әле? Интернет белән дә шулайрак. Аеруча балалар, яшүсмерләр өчен интернеттагы кайбер сайтлар куркыныч тудыра.**


vk.com

Татарстанда бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачина бер әңгәмәсендә: «Интернет уеннар аркасында үз-үзенә кул салырга омтылган очраклар да теркәлгән», – дигән иде. Былтыр Татарстаннан интернеттагы «җәрәхәтләү» төркеменә (группа порезы) кушылган бер үсмер кыз чак кына үзенә кул салмый калган булган. Психотерапевт, психолог Рамил Гарифуллин, балаларның әти-әнине социаль төркемгә алыштыруы – бик зур бәла, дип саный.

– Төркемнәр арасында төрлесе бар: позитив булганнары, суицидка этәргәннәре, секталар. Балалар арасында бәйлелеккә китерә торган тискәре йогынтылы субкультуралар элек тә булган. Хәзер халәтеңә туры килгән төркемне табуы тагын да җиңел, интернет ярдәмгә килә. Интернет уеннардан зыян күргән үсмерләр миңа еш ярдәм сорап килә, – ди Рамил Гарифуллин.

Шунысы аяныч: куркыныч тудырган сайтларны бүген ябасың, соңрак алар тагын ачыла. Шуңа да бу мәсьәләдә барысын да хокук саклау органнарына гына тапшырырга түгел, бергәләп көрәшергә кирәк.

Россиядә закон белән тыелган мәгълүматны тараткан интернеттагы сайтларны тыю максатында, бердәм реестр булдырылган. Әлеге реестр электрон формада көн саен һәм тәүлек буе эшли. Татарстан прокуратурасының балигъ булмаганнар һәм яшьләр турындагы закон үтәлешен тәэмин итү бүлеге җитәкчесе Азат Хөсәенов әйтүенчә, интернет сайтларның эшчәнлеген туктату буенча Татарстанда да ныклы эш алып барыла. Бу максатларда Татарстан прокуратурасы 2015 елда ук мәгълүмати-аналитик комплекс булдырган, ягъни интернетта хокук бозуларга каршы тору системасы реаль вакытта тыелган контентны ачыкларга, бу хакта Роскомнадзорга хәбәр юлларга һәм судка мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек бирә. Хәзер әлеге система 13 юнәлештә эшли. Наркотиклар, үз-үзеңә кул салу, комарлы уеннар, балалар порнографиясе һәм башкалар белән көрәшне үз эченә алган бу система.

– Әлеге эш башланганнан бирле, наркотикларга кагылышлы тыелган мәгълүмат билгеләре белән 13034 интернет бит табылган. Суицидка кагылышлы – 7734, балалар порнографиясенә кагылышлы 3000 интернет бит булуы ачыкланган. Мондый битләрнең эшчәнлеген туктату өчен, мәгълүматлар тиешле органнарга җиткерелгән, – ди Азат Хөсәенов.

Һәркем интернетта балаларга зыян салырлык комарлы уеннар, наркотикларга, балалар порнографисе, үз-үзеңә кул салырга этәргән мәгълүмат тупланган сайтларга юлыкса, бу хакта Роскомнадзорга мөрәҗәгать итә ала.

Әлеге оешмага килеп ирешкән шикаятьләр электрон рәвештә тегә яки бу тәртип бозу белән шөгыльләнә торган органнарга юллана, тикшерелә. Бер тәүлек эчендә шикаять буенча карар кабул ителә.

**Әлмәт шәһәренең бакчага йөрүче балалары, үзләренең тәрбиячеләре һәм автоинспекторлар белән берлектә, якты акция оештырдылар.**

## Балалар яктылыкка өнди

Алар бабайларга һәм әбиләргә яктылык кайтара торган элементлар һәм юл хәрәкәте иминлеге белешмәләре тараттылар. Өлкән яшьтә күзнең күрү сәләте, ишетү, хәлне бәяләү начарлана. Автоинспекторлар өлкәннәргә киемнәренә яктылык кайтара торган тамгалар һәм тасмалар беркетү файдалы булуын искәрттеләр. Караңгы вакытта мондый элементлар күреп алу ераклыгын бермә-бер арттыра. Балаларның да киемнәренә шушы элементларны беркетү кирәк.

**Татарстан дәүләт алкоголь инспекциясенең Түбән Кама төбәк органы хезмәткәрләре май аенда спиртлы эчемлекләр сатуның вакыт чиген бозуның 18 очрагын фаш иткән.**

## Вакытлы-вакытсыз йөрмә

Татарстанда кибетләрдә кичке 10нан иртәнге 10.00 сәгатькә кадәр спиртлы эчемлекләр сату тыела. Закон таләбен үтәмәүнең Зәйдә – 4, Түбән Камада – 11 һәм Мөслим, Сарман, Чирмешән районнарында берәр очрагы теркәлгән. Авыл кибетчеләренең аклану җаваплары бик охшаш.

Башта: «Сез нәрсә? Аракы сатмадым», – дип күзгә карап, инкарь итәләр ди. Дәлилләгәч, гаепләрен танып: «Сәгатькә карарга онытканмын», «Арыган идем шул» яки «Игътибар бирмәгәнмен», – дип акланырга тырышалар икән.

Түбән Кама кибетләре сатучыларының Дәүләт алкоголь инспекциясе хезмәткәрләре алдында керфекләре дә селкенмәгән. «Акча эшләп алырга исәпләдек. Хезмәт хакларыбыз товар сатудан кергән керемнәргә бәйле», – диләр икән.

Канунны бозган кибетчеләрнең һәркайсына административ беркетмә тутырылган. Саллы гына штраф түләгәч, икенче юлы аракы сатканда, күзеңне сәгатьтән алмассың, валлаһи.

# Казанга «зәхмәт» ташучы тотылды

**Татарстан башкаласына керү юлында полиция хезмәткәрләре Тула шәһәре кешесен тоткарладылар. Кунак булып түгел, ә ике килограммнан артык наркотик алып килгән ул.**

mvd.tatarstan.ru

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, «Малиновка» контроль-үткәрү пунктында 30 майда Мәскәүдән Казанга килүче «Лада» җиңел автомобиле туктатыла. Машинада йөртүчедән кала, тагын өч пассажир була. Ачыкланганча, алар таксига юлда утырганнар. Инспекторлар бер пассажирның үзен сәер тотуын сизеп ала. Тикшерү барышында Тула шәһәрендә яшәүче, элек хөкем ителгән 37 яшьлек ир-аттан берничә сәер төргәк табыла. Төргәкләрдәге шикле матдә Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының эксперт-криминалистика үзәгенә җибәрелә. Белгечләр 2,7 килограмм авырлыктагы төргәкләрдәге матдәнең синтетик наркотик булуын дәлилли. Бу зәхмәт 30 мең дозаны тәшкил итәр иде.

Тула кешесе кулга алынды, аңа карата Россия Федерациясе Җинаятьләр кодексының 3нче бүлегенең 30нчы маддәсе һәм 5нче бүлегенең 228.1 нче маддәсе нигезендә, җинаять эше кузгатылды. Наркотиклар ясаган, саклаган, йөрткән һәм башкаларга саткан очракта, сигез елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителү яный. Төркем белән яки вазифадан файдаланып наркотиклар таратсаң, сигез елдан 20 елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган.

ПРОГРАММА

# Спорт мәйданчыгын эләктереп кал

**Яшь чакларда без дә тау итәгендә футбол уйный идек. Капка урынына як-якка куелган таш, спорт җиһазыбыз – күне ертылып беткән һәм ярымшәлперәйгән туп була торган иде.**

Автор фотосы

Хәзерге балаларның бәхете: яхшы итеп җиһазландырылган спорт мәйданчыкларында шөгыльләнәләр. Сездә мәйданчык әле дә булса юкмы? Ул чагында тизрәк чарасын күрергә ашыгыгыз.

– Татарстан Президенты башлангычында, республикада 2013 елдан бирле «Универсаль спорт мәйданчыклары төзелеше» программасы гамәлгә ашырыла. Шәһәрләрдә һәм авылларда инде 671 спорт мәйданчыгы файдалануга тапшырылды. Бу эшләргә республика бюджетыннан 1,5 миллиард сум акча тотылды. Быел 120 мәйданчык төзелә, шуның 15е – Казанда, – диде төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Илшат Гыймаев «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Спорт мәйданчыклары җиде вариантта төзелә:

– баскетбол-волейбол һәм күнегүләр,

– мини-футбол һәм күнегүләр,

– баскетбол-волейбол, мини-футбол һәм күнегүләр,

– мини-футбол,

– баскетбол-волейбол,

– күнегүләр,

– өслеге ясалма түшәүле хоккей тартмасы, ике киенү-чишенү бүлмәсе, 100 урынга трибуна.

Республикада 11 чаңгы базасы төзелә. Алар ел әйләнәсе файдалануга яраклаштырылган. Кышын чаңгыда яки чанада шусак, җәйге айларда велосипед һәм ролик прокатлары эшләячәк.

– Корылмалар җирле үзидарәләр карамагына тапшырыла. Казанда спорт мәйданчыклары төзелешләренә иганәчеләр дә булыша. Республика буенча предприятиеләр, эшкуарлар спорт мәйданчыклары төзелешендә һәм җиһазландыруда ярдәм күрсәтергә алына икән, без моңа бик рәхмәтле генә. Спорт мәйданчыклары үзебезнең балалар, үзебезнең яшьләр өчен бит. Корылмаларны ватуга юл куймасак иде, балалар спорт белән шөгыльләнеп, сәламәт булып үссен, – дип теләде Илшат Гыймаев.

Универсаль спорт мәйданчыклары төзү киләсе елларда да дәвам итә. Җирле үзидарәләр, җирле депутатлар бу мәсьәләдә максатчанрак булсыннар иде. Үз авылыңны бушка спорт мәйданчыклы итү мөмкинлеген кулдан ычкындырмаска кирәк.

**Дамир БӘДРИЕВ.**

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

# «Юлда сату карта уены кебек»

**Юлга чыксам, транспорт тәрәзәсеннән күзәтеп барырга яратам.**

Бу юлы да командировкага барганда, М7 трассасында аллы-гөлле кием-салым сатучылар күзгә ташланды. Гадәттә, кукуруз таякчыклары, каклаган каз, ысланган балык сатканнарын еш күрергә туры килә. Ә монда мамык шәлләр, оекбашлар саталар. Бер сатучы янында туктап алдык. Редакциядән икәнлегебезне белеп:

– Кайда сатканыбызны гына язмагыз. Болай да көн юк безгә. Хәзер килеп тикшереп китәләр, – дип каршы алды безне сатучы хатын.

**– Ник тикшерәләр соң? –** дим.

– Төрле төсле киемнәр белән шоферларның игътибарын җәлеп итәсез, юл һәлакәте килеп чыгарга мөмкин, диләр. Бәйләнергә сәбәп табалар инде, – ди исемен әйтергә теләмәгән апа.

Казаннан ук килеп сата икән, хәзер пенсиядә, машинаны да үзе йөртә.

**– Бу шәлләрне үзегез бәйлисезме?**

– Җиде яшемнән бәйлим. Дөрес, товарларның күбесен башкалардан сатып алам. Оекбашны 120 сумга алам, 250гә сатам. Башкача булмый. Бензин бәясен дә чыгарырга кирәк бит. Шәлләрем 2000 сумнан башлана. Төрле төстәге челтәрләп бәйләнгәннәре 500 сумга да бар.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

**– Монда әйбер сата аласызмы соң?**

– Кайчан ничек. Карта уенындагы кебек. Уңыш елмайса сатыла, безнең көн түгел икән, көне буе басып торып бер әйбер сатмый калган чаклар да бар.

**– Соң, файдасы да юктыр бит алайса?**

– Ничек дип әйтим инде, бер айлык хезмәт хакы кебек килеп чыга инде. Пенсия акчасына гына яшәве авыр бит…

**Эльвира МОЗАФФАР.**

*Чәршәмбе көнне хезмәттәшебез Илфак Шиһаповны соңгы юлга озаттык.*

*Хушлашу мәрәсименә халык агылды гына... Алар барысы да Илфакның иҗатын, шәхесен хөрмәтләп, күңел кушканга килгән кешеләр иде. Мәрхүмнең рухына җылы сүзләр әйтелде, аны «уникаль шәхес», «искиткеч талантлы кеше», «ярдәмчел дус» дип атадылар. Кызганыч, боларның барысын да хәзер «иде» дип сөйләргә мәҗбүрбез. Киң күңелле, чиста йөрәкле, ярдәмчел, талантлы татар улын югалттык шул.*

*Мәрхүм туган ягы – Лениногорск районының Иске Иштирәк авылында җирләнде. Анда Казаннан, Башкортстаннан, Самарадан дуслары килгән иде.*

*Илфак Шиһаповны соңгы юлга озату мәрәсименә килгән һәркемгә, аны оештыруда ярдәм иткән дуслары – Рәшит Ваһапов фонды җитәкчесе Рифат Фәттаховка, «Аксу» продюсерлык үзәге җитәкчесе Рөстәм Сәрвәровка, Инсаф Хәмитовка, Илшат Ханбиковка, журналист Данил Сәфәровка рәхмәтебезне җиткерәбез. Ходай сезгә хәерле, озын гомер бирсен!*

***«Шәһри Казан» редакциясе коллективы.***

## Стилист-шоппер Руфинә:

# «Бүгенге киенү модасында юморга урын бар»

**Руфинә Галинурова мәктәп, студент елларында ук киенү стиле белән калганнардан аерылып торган. Күңеленә яткан әйберне кибеттән тапмаса, тиз арада үзе теккән. Шуңа да филология факультетын тәмамлап, стилист булып эшләвенә аны белгәннәр бер дә аптырамый. Бу – аның яраткан эше.**

Руфинә – гади генә стилист түгел, ә стилист-шоппер. Кем соң ул стилист-шоппер? Ул синең белән сәүдә үзәкләрендә йөреп, сиңа килешле киемнәр, образлар сайлаучы. Гадәти булмаган сирәк һөнәр, әмма бүгенге көндә аңа ихтыяҗ зур.

– Хәзер кибетләрдә әйбер шулкадәр күп, кеше, еш кына, кайсысын сайларга белми, югалып кала. Мин әнә шундыйларга ярдәм итәм. Башта клиент белән очрашам, аның нәрсә теләгәнен тыңлыйм һәм ул миңа 100 процент ышангнын күрсәм, эшкә алынам. Очрашуда шоппингның бюджеты, нинди киемнәр алачакбыз – сүз шул турыда бара. Иң мөһим фактор – клиент нинди стильдә киенергә тели, чөнки стильләр бүгенге көндә бик күп: классика, авангард, гранж, гламур, кантри, кэжуал һ.б. Сөйләшеп бетергәч, кибетләргә юл тотабыз. Гадәттә, 2-2,5 сәгать эчендә бар теләгән әйберне дә алабыз, – ди Руфинә.

Руфинә кайбер клиентларына стильләрен бөтенләй башка төрлегә үзгәртергә киңәш итә. Аның фикеренчә, стиль ул – хәтта булачак тормышыңны да хәл итә торган мөһим фактор. Мәсәлән, кияүгә чыгарга теләгән кызларга ул «романтик» стильне сайларга киңәш итә. Матур күлмәк, билдә «утырган» купшы итәккә ир-атларның барысы да игътибар итәчәк, ди ул. Үзе дә, хиппи, рок-н-ролл, спорт шик стильләреннән соң «романтик»ка күчкәч, булачак тормыш иптәшен очрата. «Мөгаен, хиппи кебек киенгән булсам, ул миңа әйләнеп тә карамас иде», – ди стилист.

– Әлеге өлкәдә шөгыльләнә башлаган елларда, эшем күпләргә сәер тоела иде. Янәсе, нинди кыенлыгы бар, нәрсәгә ул стилист-шоппер, кирәк киемне барасың да аласың. Әмма безнең республикада мода журналларының нәшер ителә башлавы, телевизордан «Модный приговор» кебек тапшыруларның еш күрсәтелүе стилист белән кибеткә йөрү модасын алып килде. Кибеткә йөрүдән тыш, клиентларның өенә барып, гардеробларына ревизия дә ясыйм. Күпләр кием өстенә кием алып, аны нәрсә белән бер-берсенә килешле итеп кияргә дә белми. Булган киемнәрдән образлар җыям, нәрсә җитми, аның исемлеген төзеп, кибеткә чыгабыз. Гардеробта кешене картайта торган, тән төзелешенә туры килмәгән кием булса, мин аны бөтенләй ыргытырга киңәш итәм. Андый киемне саклаудан файда юк, урын гына алып торачак. Хатын-кызның гардеробы белән уртак тел табу авыр түгел, ә менә ир-атлар белән күпкә катлаулырак. Монда кием аның йөзенә генә түгел, ә җәмгыятьтәге статусына, машинасына, эшенә, яраткан шөгыленә дә туры килергә тиеш.

Һәр хатын-кыздагы проблема ул – шкаф тулы әйбер, әмма кияр кием юк. Югыйсә, матур кием, әмма алар килешми. Андый әйберләрнең җыелуы ул – эмоциональ шопингның нәтиҗәләре. Шәп кәеф белән кибетләрдә йөрисең һәм күзгә ташланган һәр матур әйберне сатып аласың. Ул вакытта: «Бу киемне нәрсә белән киярмен?» – дигән сорау башта бөтенләй дә тумый. Тагын бер сәбәбе – ул әлеге киемне кемдәдер күреп, килешәме-юкмы икәнен уйлап тормый гына, аны сатып алу. Кибеттә йөргәндә «Җиде кат үлчә, бер кат кис» әйтеме буенча гына әйбер алырга кирәк. Әйберләр 100 процент килешкәнен һәм ул сиңа бик кирәк икәнен белгән очракта гына гардеробыгызны тулыландырыгыз, – ди стилист-шоппер.

Хәзер модада – стильләрне берләштереп киенү. Мәсәлән, күлмәк белән уңайлы кроссовка кию, җитди пиджак белән ертык джинс чалбар һәм кедалар... Сиңа карап, бу сәгатьләр буе җыенган икән, дип уйларлык булмасын. Янәсе, шкафыңны ачкансың да, күзеңә нәрсә ташланган – шуны кигәнсең. Бүгенге киенүдә юморга урын бар, образың кызык булсын. Ә төсләргә килгәндә, аның модасы булмый. Монда – кемгә нинди төс килешә. Зәвык белән киенү – һәрчак модада.

Баксаң, стилист-шоппер белән кибетләргә йөрү – акчага экономия икән ул. Беренчедән, син кирәк булмаган әйберне сатып алмыйсың. Икенчедән, стилистта бар кибетләрнең дә ташлама карточкалары бар. Һәм, әлбәттә, син вакытыңны бушка сарыф итмисең, тиз арада күз явын алырлык образда булачаксың. Ә матур булу мөһим, чөнки кая барсаң да, киемеңә карап каршы алалар.

**Азалия ИСМӘГЫЙЛЕВА.**

# «Илдус кебек талантларны сакларга кирәк»

**Камал исемендәге театрда узган Татарстанның халык артисты Илдус Габдрахмановның юбилей кичәсендә алма төшәрлек тә урын булмавы гаҗәп түгел, чөнки тамашачы аны ярата, хөрмәт итә. Артистка премьер-министрның Рәхмәт хаты, шәһәр мэрының Мактау грамотасы тапшырылды.**

vk.com

Иң элек заманында Илдус уйнаган «Биюче» спектаклен кабат искә төшерделәр. Илдусны котларга Башкортстаннан Гафури исемендәге театр артистлары, якташлары, сыйныфташлары килде. Алар арасында Апастагы театр түгәрәге җитәкчесе Миләүшә Алиуллина да бар иде.

– Халыкның яраткан артисты булу ул – зур бәхет. Синең бәхетеңне күреп, мин сөенәм. Балачакта син йөргән «Мушкетерлар» театр коллективы бүген дә бар. Син аларның горурлыгы, – диде Миләүшә ханым.

Ул укучысы өчен горурлануын яшермәде.

Кичәдә Илдус уйнаган кинолардан өзекләр күрсәтелүе дә очраклы түгел. Моннан берничә ел элек Мөселман кинолары фестивалендә ул «Хлопнул дверью и ушёл» дигән кыска метражлы фильмда «Иң яхшы ир-ат ролен башкаручы» буларак танылган иде. Юбилярны тәбрикләргә Мәскәү режиссерлары да килде. Шуларның берсе – Василий Антипов.

– Илдус ул – диапазоны чикләнмәгән актер. Аның кебек талантларны сакларга кирәк, чөнки талант яхшы җирлектә генә үсә, – диде ул.

Илдус белән Мәскәүдә укыган щепкинчылар котлауларын җыр аша җиткерде. Училищеда татар теле һәм әдәбияты укыткан Нәзифә Кәримова да үзенең истәлекләре белән уртаклашты. Илдусның татар театры сәхнәсенә яңа жанр – татарча степ биюен алып килүен аның зур уңышы дип бәяләде. Татарстанның халык артисты Әсхәт Хисмәтов та үзенең моңлы халык җырын бүләк итте. Камаллылар исеменнән артистны режиссер Фәрит Бикчәнтәев тәбрикләде.

– Театрда дуслар була алмый, диләр. Илдус – минем чын дустым. Илдусны бию белән сихерләгән кеше дә мин идем. Ләкин син биюче түгел, драма артисты. Син минем өчен иң кадерле дустым, артистым, – диде Фәрит Бикчәнтәев.

**Люция ХӘБИБУЛЛИНА.**

# Тукайга сәяхәт

**Казанның Идел буе районындагы 100нче мәктәбендә һәм анда урнашкан балалар бакчасында ел саен апрель аенда бөек шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган чаралар гел булып тора. Әле күптән түгел үткән чарада республика семинарына килгән татар теле укытучылары һәм тәрбиячеләр дә катнашты.**

– Беренче чиратта педагогларыбызның эшен күрсәтәсебез, башкалар белән уртаклашасыбыз килде. КФУ профессоры Гөлшат Галиуллина да чарабызга теләп килде, – ди мәктәп директоры Рәхилә Абдуллина.

Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр һәм мәктәп укучылары, педагоглар «Тукай тормышына сәяхәт» исемле сәхнәләштерелгән күренешләрдә катнаштылар. Алар килгән куначкларны, әти-әниләрне, балаларны 131 ел элек булган вакыйгаларга, кичерешләргә алып барып кайттылар. Кечкенәләр өчен «Тукай әкиятләренә сәяхәт» исемле интерактив уен да оештырылды. Алар үгетнәсыйхәт биргән, тәрбиягә өйрәткән шигырьләрне сәхнәләштерделәр. Укучылар һәм укытучылар бәйрәмдә бик теләп катнашты. Мондый бәйрәмнәр хезмәтне сөяргә, туган илеңнең, торган җиреңнең кадерен белергә өйрәтә. Әсәрләр ихтирам, әдәп, намус кебек сыйфатлар тәрбияли. Тукай татар, рус, инглиз телләрендә яңгырады. Халкыбызның җырлы-биюле уеннарын да искә төшердек. Китапханә хезмәткәрләре белән берлектә бәйге дә оештырдык.

Адилә **НИГЪМӘТУЛЛИНА.**

ПОЧТАДАН

# Җәмилә җенләнсәме?

Татар Талкышы авылы мәдәният йортында, авыл үзешчәннәре көче белән, «Җәмиләнең җенләнүе» (Фоат Садриев әсәре буенча) исемле спектакль куелды. Әсәрдәге вакыйгалар хәзерге заман килене Җәмилә (Гөлназ Исмәгыйлова) белән Миңлебикә атлы каенана (Рәмзия Сафина) тирәсендә кайный. Башка артистлары – Әминә Мусина, Рамилә Сатдарова, Гөлнәфис Гафиятуллина, Гөлсинә Камалова, Гөлчәчәк Сафиналарның уйнавын тамашачы алкышларга күмде. Чын артистлардан бер дә кимен куймадылар. Тормыш мәшәкатьләрен бер читкә куеп, авыл халкына күңелле мизгелләр бүләк итәр өчен бик күп көч куйды алар. Кечкенә генә әсәрне сәхнәләштереп, тамашачыга җиткерү өчен дә зур тырышлык һәм осталык кирәк шул. Шуңа да үзешчәннәребезнең спектакльләр куюы, сәхнә күренешләре әзерләве аерым мактауга лаек.

Суфия **БАГАУТДИНОВА,**
авыл китапханәсе методисты,
Чистай районы.

# Авырудан «дәва»

Бу вакыйганы күптәннән ишетеп беләм. Сания апа белән Хәбир абый тату гына яшәп ятканда, ир авырып киткән. Табиблар кушканны төгәл үтәсә дә, дарулар эчсә дә, дәвасын тапмый Хәбир абый. Ләкин бирешми, төрле дәвалану юлларын эзләп карый, өметен өзми, гел көрәшә. Ахыр чиктә хәтта денатурат эчә. Ни хикмәт, ул терелә. Табиблар да бабайның савыгуына шаккаталар. Авырган кешегә денатурат эчәргә куша икән бу дип уйламагыз тагын. Денатуратта түгел хикмәт. Терелүенә ышанганга, көчле рухлы булганга, өметен өзмәгәнгә авыруын җиңә алган Хәбир абый. Тормыш безне сынау алдына куйганда, төрле авырлыклар биргәндә югалып калмасак иде, ахыргача көрәшик.

Миңлегөл **ӘДҺӘМОВА,**
Казан.

СОРАУ-ҖАВАП

*Мал калдыклары бакча артына гына сыймый башлады. Күпләп терлек асраучы кешеләргә нишләргә? Тиресне авыл башындагы чүплеккә генә ыргытсаң буламы?*

**Рәзинә Әхмәтҗанова,**
Балык Бистәсе районы.

**Идрис ГАТИН,** Татарстан Республикасы буенча Россельхознадзор идарәсенең дәүләт ветеринария күзәтүе бүлеге җитәкчесе:

– Тирә-якта крестьян-фермер хуҗалыклары, колхоз, ЛФХ җирләре булырга тиеш. Сөйләшеп, мал калдыкларын шуларның пай җиренә чыгарып була. Тиреснең янган, ягъни черемәгә әйләнгән булуы шарт. Бу очракта бернинди контроль органнары да сүз әйтмәячәк. Тиреснең кар эрегәнче чыгару яхшы. Тавык, дуңгыз тизәге аеруча да сасы исле. Аларны изелгән, черемәгә әйләндерелгән хәлдә генә кабул итәләр. Торак пункттан ике-өч чакрым ераклыкта булган кырларга гына чәчәләр. Районнарда тиресне ферма тирәсендә дә җыялар. Тиресне тиешсез урыннарга чыгару тыела.

# Гөлсәриядән кычытканлы сөтле аш

**Быелгы сыман кычытканны беркем дә көтмәгәндер. Хәйран ялындырып кына баш төртте ул. Җәйне, яшеллекне шул тиклем юксындык, хәтта кычытканны әнә шулай көтеп алдык.**

Зөлфия Хәлиуллина фотосы

Кычыткан ашы да сагындырган икән. Аны һәркем үзенчә пешерә, яз көне ким дигәндә өч тапкыр ашап калырга тырыша. Күп төрлесен ашаган да, күргән дә бар, шулай да Балтач районы Сосна авылыннан Гөлсәрия Сабитованың кычыткан ашы бөтенләй үзгә кебек тоелды. Сезгә дә тәкъдим итим әле. Гөлсәрия аны сөттә пешерә икән. Сөт кайнап чыккач, кыздырып суган салабыз, берничә генә бәрәңге турыйбыз һәм аз гына дөге салып җибәрәбез. Дөге пешеп җиткәндә кычыткан, укроп, яшел суган салабыз.

– Яз көне бәрәңге бик тәмле булмый. Бәрәңгеле аш яратсагыз, дөге салмагыз, бераз гына йомырка туглап җибәрсәгез дә була, – ди Гөлсәрия.

Зәлия **ЗЫЯТДИНОВА.**

**Казанда «Милләт йорты» кафесы хуҗасы Рәүф хәзрәт Хәсәнов аксакалларны җыеп аш үткәрде. 2011 елны Рәүф әфәнде, җимерелеп беткән, Габдулла Барудиның әтисе үз заманында төзеткән «Милләт» типографиясен сатып алганда, үзенең 1 миллион сум хәләл акчасын артыграк түләгән, чөнки башка милләттән бер кеше аукционда ул бинаны кыйммәткәрәк алмакчы булган.**

# Малның бәрәкәтлесе кадерле

Рәүф әфәндегә юмартлыгы ярдәм иткән. Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан һәм башка татар зыялыларының эзләрен саклаган «Милләт» типографиясе бүген милләтнең йөзек кашына әйләнеп бара. Монда кешеләр шактый очсыз хакка ашап чыгу өчен генә йөрми, мосафирлар кунарга да кала икән. Бүгенге көндә «Милләт йорты» кафесы Рәүф хәзрәтнең элеккерәк вакытларындагы кебек изге гамәлләрен искә алып, Казан Аксакаллар шурасы рәисе Рәүф Ибраһимов, шура әгъзалары Илһам Миндубаев, Әсһәр хәзрәт Вәлиуллин һәм башкалар үз куллары белән эшләп тапкан малның бәрәкәтле булуына басым ясап әйттеләр. Рәүф әфәнде, узган корбан бәйрәмендә шушы кафеда табыннар әзерләп, 100дән артык кешене кунак иткән. Бу юлы да, үзе тапкан ризыкны кешеләр белән бүлешүдән хуҗаның малы кимемәсен, арта гына төшсен, диделәр мәҗлестәгеләр. Соңыннан, Аллаһның бездән һәм малларыбыздан разый булуын теләп, дога кылдык. Рәүф әфәнденең дүрт улы бар, алар да әти-әниләре үрнәгендә саф татар телендә сөйләшәләр, намаз укыйлар, изге гамәлләр кылып яшәргә омтылалар.

Рәис **МӨКАТДИСОВ,**
Казан Аксакаллар шурасы рәисе.

# Безнең гомер, яшен уты кебек, Тау сыртларын айкап юл ала

**Елена Бурундуковская – рус телендә иҗат итүче шагыйрәләребезнең берсе. Ул яшәеш өчен бик тә мөһим булган хакыйкать, күңел матурлыгы, изгелек кебек сыйфатларны алга куя. Аның әсәрләрендә без уйланучан, ярдәмчел, вөҗданлы кеше образын күрәбез. Шул ук вакытта табигатькә, ел фасылларына, музыка сәнгатенә мөнәсәбәтле миниатюралары да бик җылы тәэсир калдыра. Бүген газетабызда аның кайбер әсәрләрен Индус Сирматов тәрҗемәсендә тәкъдим итәбез.**

**Елена БУРУНДУКОВСКАЯ**

* * *

*Тормышымның дәреслеген язам.*
*Язамын да ертам битләрен.*
*Кабатлаулар монда кирәк түгел,*
*Өлгерәлми калсам нишләрмен.*

*Белмәк булам – кем мин, кая барам,*
*Бу дөньяда мине кем тота.*
*Ярый әле таныш йолдыз биргән*
*Өмет нуры мине җылыта.*
*Үткән белән киләчәкне уйлап*
*Баш катырмыйм, мәгънә юк анда.*
*Шушы көнем, бары шушы мизгел*
*Кирәк миңа бөтен җиһанда.*
*Бу мизгелдә дөнья хакиме мин,*
*Үз язмышым – минем кулымда.*
*Әрнү, сыкрау катыш үткән еллар*
*Әсир бүген минем учымда.*
*Тиздән, менә тиздән аңлармын күк*
*Бу тормышның тирән мәгънәсен.*
*Капламасын гына күзләремне*
*Гүзәл билгесезлек пәрдәсе.*

* * *

*Нарат исе килгән балачакта*
*Ял итәбез елга буенда.*
*Нәни канатларын җилпи-җилпи,*
*Бер күбәләк куна кулыма.*

*Елга тирәнлеген искәрмичә,*
*Йөзеп, чумып анда уйныйбыз.*
*Могҗизага әле ышанабыз,*
*Дөнья мәңгелек дип уйлыйбыз.*

* * *

*Үткәнем дә юк, киләчәгем дә,*
*Күкне күзәтеп торам тын гына.*
*Тәрәзә рамын чуарлап, бизәп,*
*Кыйгачлап ява бары кар гына...*

*Кабарган түшәк төсле ак болыт*
*Күккә эленгән бер рәсем булып...*
*Ялгызым тойган иркә мизгелем,*
*Тукта, ашыкма, көт бераз гына.*

*Үткәнем белән киләчәгемнең*
*Нәкъ уртасында торам түгелме?*
*Язмышымы соң бу, иркә мизгелме,*
*Җан әрнетүче хисләр генәме?*

* * *

*Уйланам: авыр кичүне*
*Яңа көннәргә.*
*Үткәнемнән калган миңа*
*Бары күләгә.*

*Калган бары йөрәгемнең*
*Ярсуы гына.*
*Калган тагын учагымның*
*Ялкыны гына.*

*Шулчак нәрсәдер зеңгелди*
*Тәрәзгә тиеп.*
*Мәче мияулый икән бит,*
*Яз җитте, диеп.*

**УРАЛ**

*Урал минем алда урала да*
*Болытларга кереп чуала.*
*Корыч тасма төсле*
*бормалы юл*
*Тау итәкләренә чорнала.*

*Тоннельләре тулы эңгер-меңгер,*
*Кыяларның очы кырылган.*
*Урал тауның табигате төсле*
*Җәйрәп ята каты токымнар.*

*Безнең гомер, яшен уты кебек,*
*Тау сыртларын айкап юл ала.*
*Киңлекләргә чыгып тын ала да*
*Мәңгелеккә кереп югала.*

* * *

*Син, яратам, дигәч пышылдап,*
*Нурлар чәчә төнге тәрәзәм,*
*Ай бишеккә басып тирбәлә,*
*Аннан күккә аша тәгәрәп.*

*Син, яратам, дигәч пышылдап,*
*Кулларыңа синең кагылам,*
*Иркәләвең җанны эретә,*
*Күзләреңә карап табынам.*

*Син, яратам, дигәч пышылдап,*
*Мин дә шул ук сүзне*
*кабатлыйм.*
*Вакыт очып үтә сиздерми,*
*Киң галәмдә икәү калабыз.*

*Бер елмы бу, әллә мизгелме,*
*Илаһи бер көчкә ия без.*
*Шөбһәләнеп сөю аралаш,*
*Татлы бәхет эзли йөрәгем.*

* * *

*Тирә-ягым инде шәрә калган*
*Агачларым койгач яфрагын.*
*Ерак-ераклыклар якын сыман,*
*Аермачык күренә офыгым.*

*Табигатьнең кануннарын үтәп,*
*Дөнья йоклар иде тын гына,*
*Көзге җилнең әче сызгыруы*
*Яңгыр шаулавына кушыла.*

*Ә агачта калган соңгы яфрак,*
*Сары яфрак, ялгыз, бердәнбер.*
*Ул көрәшкә чыккан җилләргә дә,*
*Тормышка да каршы бергә-бер.*

# Күзле бүкән

**Әле генә күргән төшеннән куркудан, аның тыны кысылды. Ул, кемгәдер нәрсәдер әйтергә теләп ярсый-ярсый, авыз эченнән мыгырданды. Куллары белән кемнәрнедер этәкләде-төрткәләде. Кемнәрнедер аяклары белән типкәләде. Үрсәләнеп газаплана торгач, ниһаять, аңына килә башлап, җан авазы белән ачыргаланып: «Юк, юк! Бу безнең балабыз түгел», – дип, иңри-иңри, шабыр тиргә баткан хәлдә уянып китте. Әле үзе теле белән әйтерлек хәлдә булмаса да, куллары белән битен каплап: «Йа Ходаем, мондый бала бирә күрмә, бирә күрмә, бирә күрмә», – дип ялварды. Аның үксеп-үксеп елавыннан аккан күз яшьләре бармаклары арасыннан саркып чыгып, аска тәгәрәде. Эченнән бөркеп чыккан кайнар сулышы тамак төпләрен, сулыш юлларын пешереп үтте. Ниндидер бер илаһи көч аның йөрәген умырып-умырып алгандай итте, җанын сыкратты, күңелен изалады.**

Хатын, кабаланып, кулларын корсагы астына куйды. Туктаусыз үксүдән, үзенең карынында яткан баласының арлы-бирле килеп чайкалганын тойды. Әйтерсең лә бала, хәрәкәтләр ясап, әнисенә нидер әйтергә тели. Ана исә, аска салынып төшкән корсагын куллары белән кочып: «Юк, юк. Син төшемдә күргән гарип бала түгел. Син сау-сәламәт хәлдәге үз балабыз», – дип ыңгыраша.

Хатын үзенең әле генә күргән төшен иренә бөлдерергә теләмәсә дә, ире берничә минут элек булып үткән бу хәлләрне аңы белән сизеп, күңеле белән күреп ята кебек иде. Ул кинәт кенә торып, хатынының калтыранган гәүдәсен кочагына алып:

– Җанкисәккәем, ни булды? Нәрсәдән куркып болай калтырыйсың? Әллә берәр җирең авыртамы? – диде.

– Юк, бер төшем дә авыртмый. Мин бик начар, акылдан язарлык төш күрдем. Ул яман төшне хәтта сөйләргә дә куркыныч. – Хатын, ире китереп биргән суны йоткалап, сүзен дәвам итте. – Имеш, мин аяксыз-кулсыз, җитмәсә кара-кучкыл бала тапканмын. Аның күзләре ут сыман янып тора. Карашлары – җаныңны көйдереп алырлык ялкынлы, төсе-бите – олы кешеләрнеке кебек җитди, кырыс, таләпчән...

Ләкин хатын төшләнгәндә, тегеләнеп, баланың: «Мин синең бөтенләй башка континент кешесеннән туган җимешең булам», – дигәнен иренә әйтмәде.

– Төшкә ни кермәс. Зинһар, тынычлана күр. Балабызга зыяны тия күрмәсен, – дип, ире хатынының карын тирәләрен бисмилла әйтеп сыпырды да сыпырды.

Ир бу сәер төшне хатынының берничә мәртәбә күреп саташуын, әлбәттә инде, белмәде. Хатын да төштәге таныш күренешләрне кино караган кебек итеп, тыныч уздырырга тырышты.

Ниһаять, хатын соңгы көннәрен бала табу йортында, табибләр күзәтүе астында булып, борчылып-хәвефләнеп, кылган гөнаһларының тиз көндә мәгълүм буласыннан куркып уздырды. Кич була да таң ата, таң ата да көн туа дигәндәй, бала да дөньяга аваз салды. Ана, бик авырлык белән тапкан баласыннан соң хәле үтә мөшкел булса да, баласын үзенә күрсәтүләрен үтенде. Ул, татар чырайлы малаен күреп, һуштан язды.

Вестибюльдә шашар хәлгә җитеп типкән йөрәген тынычландыра алмыйча, тыпырчынган җанын, үзен кая куярга белмичә арлы-бирле йөргән ир каршына ак халатлы, көләч йөзле бер ханым килеп басты. Ул, ихластан елмаеп:

– Тәбрик итәм сезне, хатыныгыз менә дигән ир бала тапты, – диде.

Бу шатлыклы хәбәрне ишетүдән чак кына башы әйләнеп киткән, әле аңына килеп җитмәгән ир:

– Аяклары, куллары бармы? – дип сорады.

– Бар, аяклары, куллары да, башка җирләре дә бөтен, исәнсау, Ходайга шөкер, – диде ханым.

Ир, аякларының туктаусыз калтыравыннан хәле китеп, каршыдагы диванга барып ауды. Ул моңарчы җанын, тәнен басып торган билгесезлектән котылып, бушанып калды. Үзенең әти булуын аңы-зиһенә аша үткәрерлек дәрәҗәдә түгел иде әле ул.

**Рәис САФИН.**

**Уважаемые акционеры!**

23.05.2017г. на заседании Совета директоров Открытого акционерного общества «Аш-Су», которое находится по адресу: Пр.Победы, д.116, принято решение о проведении годового общего собрания акционеров в форме совместного присутствия акционеров.

Собрание состоится **27.06.2017** года по адресу: Пр.Победы, 116 в офисе ОАО «Аш-Су»

Начало собрания: **12 часов.**

Собрание проводится в форме совместного присутствия акционеров для обсуждения вопросов повестки дня ОАО «Аш-Су» и принятия решений по вопросам, поставленном на голосование.

Время начала регистрации участников годового общего собрания акционеров: **10 часов**.

Список акционеров, имеющих право участвовать на годовом общем собрании акционеров, составлен на основании данных реестра акционеров по состоянию на 02.06.2017 года.

**Повестка дня годового общего собрания акционеров:**

1. Определение порядка ведения годового Общего собрания акционеров.
2. Утверждение годового отчета, годовой бухгалтерской (финансовый) отчетности, распределение прибыли и убытков по результатам за 2016 год.
3. Избрание Совета директоров Общества.
4. Избрание Ревизионной комиссии Общества.
5. Утверждение аудитора Общества.
6. Принятие решения о согласии на совершение крупной сделки.

С материалами к годовому общему собранию акционеров можно ознакомиться с 02.06.2017г. по адресу: Пр.Победы, 116 в офисе «Аш-Су» в рабочие дни с 9-00 до 16-00. Контактный телефон: **262-03-68**.

Участнику общего собрания акционеров необходимо иметь при себе паспорт или иной документ, удостоверяющий личность, а для представителя акционера необходимо также иметь доверенность на право участия в общем собрании акционеров и (или) документы, подтверждающие его право действовать от имени акционера без доверенности.

Совет директоров ОАО «Аш-Су»

**ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ О СОГЛАСОВАНИИ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА**

Кадастровым инженером Алкиным Марселем Ревовичем, 422330, РТ, Кайбицкий район, с. Старые Чечкабы, ул. Советская, д.50, aaa89179118990@mail.ru, 89179118990, кв. атт. № 16-11-391.

В отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:260104:22, расположенного Республика Татарстан, г. Казань, Советский район, п. ИЖС Ассоциации «Агроинвестор», ул. Ноксинская, дом 7, выполняются кадастровые работы по исправлению кадастровой ошибки в местоположения границы и площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Зарипов Р.Р., РТ , г. Казань, ул. Ноксинская, д. 7, т. 89274038768.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: РТ, г. Казань, ул. В. Кулагина, д.10, оф.224. 02 июля 2017г. в 8 часов 30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: РТ, г. Казань, ул. В. Кулагина, д.10, оф.224. Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 2 июня 2017г. по 2 июля 2017г. по адресу: РТ, г. Казань, ул. В. Кулагина, д.10, оф.224.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы: 16:50:260104:11 (РТ, г Казань, Советский район, п. Малые Клыки, ул. Ноксинская, уч.5), 16:50:260104:23 (РТ, г. Казань, Советский район, тер Асс. «Агроинвестор», ул. Ноксинская,д.9), 16:50:000000:21246 (РТ, г. Казань).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяюший личность, а также документы о правах на земельный участок. Ваша явка или явка Вашего представителя с доверенностью, подтверждающей его полномочия участвовать в установлении границ земельного участка и подписывать соответствующие документы, необходима. Ваше отсутствие или отсутствие Вашего представителя не является препятствием для проведения работ по согласованию границ земельного участка.

**ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ О СОГЛАСОВАНИИ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА**

Кадастровым инженером Алкиным Марселем Ревовичем, 422330, РТ, Кайбицкий район, с. Старые Чечкабы, ул. Советская, д.50, aaa89179118990@mail.ru, 89179118990, кв. атт. № 16-11-391.

В отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:171641:8, расположенного Республика Татарстан, г Казань, Приволжский район, ул Земледельческая,д.20, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границы и площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Перцева Л.Г., РТ , г. Казань, ул. Малая Красная, д. 6, т. 89872977820.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: РТ, г. Казань, ул. В.Кулагина, д.10, оф.224. 02 июля 2017г. в 9часов 00 минут.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: РТ, г. Казань, ул. В. Кулагина, д.10, оф.224. Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 2 июня 2017г. по 2 июля 2017г. по адресу: РТ, г. Казань, ул. В. Кулагина, д.10, оф.224.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы: 16:50:171641:15 (РТ, г. Казань, Приволжский район, ул. Земледельческая,д.18), 16:50:171641:14 (РТ, г. Казань, Приволжский район, ул. Земледельческая, д.22), 16:50:171641:12 (РТ, г. Казань, Приволжский район, ул. Рубежная,д.11)

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяюший личность, а также документы о правах на земельный участок. Ваша явка или явка Вашего представителя с доверенностью, подтверждающей его полномочия участвовать в установлении границ земельного участка и подписывать соответствующие документы, необходима. Ваше отсутствие или отсутствие Вашего представителя не является препятствием для проведения работ по согласованию границ земельного участка.

**НУЖНЫ ДЕНЬГИ –**
плохая кредитная история –
ты в черном списке? –
отказывают в кредите ЗВОНИ!
**8-904-666-68-68, 8-951-893-63-22.**
ООО «Микрокредитная компания «АльтернативА» ОГРН 1141690089650
Реклама

## Менә сиңа «койрык»!

1843 елның 5 февралендә астронавтлар бик тә зур кометаны ачалар. Аны «Великая» дип атыйлар. Җир яныннан үтеп киткән бу кометаның койрыгын кешеләр бер ай дәвамында күзәтә алганнар. Кометаның озынлыгы 800 миллион километр булган.

# Внимание: нефтепровод!

**Альметьевское районное нефтепроводное управление доводит до сведения всех руководителей, совхозов и колхозов, всех жителей городов и районов, что на территории Альметьевского, Бугульминского, Лениногорского, Новошешминского,Чистопольского, Алексеевского, Тукаевского, Заинского, Сармановского, Актанышского, Мензелинского, Муслюмовского, Азнакаевского, Ютазинского и Нижнекамского районов проходят магистральные нефтепроводы большого диаметра, обозначенные специальными опознавательными знаками.**

В целях обеспечения сохранности магистральных нефтепроводов, создания нормальных условий их эксплуатации и предотвращения несчастных случаев «Правилами охраны магистральных трубопроводов», Постановлением № 367 Кабинета министров Республики Татарстан «О мерах по обеспечению безопасной эксплуатации и повышению надежности работы магистральных нефтепроводов по транспортированию углеводородного сырья и баз их хранения» и другими руководящими документами установлена охранная зона вдоль трассы трубопроводов шириной 25 метров в каждую сторону от оси крайних нефтепроводов. В охранной зоне магистральных нефтепроводов без письменного разрешения и согласования с Альметьевским районным нефтепроводным управлением.

**ЗАПРЕЩАЕТСЯ:**

- Возводить любые постройки и сооружения, производить всякого рода горные, карьерные, строительные, монтажные и взрывные работы.
- Выполнять земляные и мелиорационные работы.
- Располагать полевые станы, загоны для скота, складировать корма, удобрения, материалы, скирдовать солому и сено, сажать деревья и кустарники, размещать культурные, коллективные сады и огороды.
- Устраивать стрельбища и размещать свалки.
- Перемещать, сносить и производить засыпку грунтом, переставлять и повреждать опознавательные, запрещающие и другие знаки и контрольно-измерительные колонки.
- Открывать крышки, люки, калитки, двери и замки колодцев, ограждений узлов линейной арматуры, блок-боксов, установок катодной защиты.
- Разводить огонь и размещать любые закрытые и открытые источники огня.

В охранной зоне запрещается проводить любые мероприятия, связанные со скоплением людей, не занятых выполнением разрешенных в установленном порядке работ.

Полевые сельскохозяйственные работы в охранной зоне нефтепроводов производятся землепользователем после предварительного уведомления предприятия, эксплуатирующего трубопроводы.

Проезд автотракторной техники через нефтепровод допускается только по специально оборудованным переездам и дорогам общего пользования с твердым покрытием.

**ВСЕ РАБОТЫ В ОХРАННОЙ ЗОНЕ НЕФТЕПРОВОДА ПРОИЗВОДЯТСЯ ТОЛЬКО В ПРИСУТСТВИИ ПРЕДСТАВИТЕЛЯ НПС.**

**К лицам, виновным в нарушении Правил охраны магистральных трубопроводов, если эти действия по своему характеру не влекут уголовной ответственности, могут быть применены в качестве меры административного взыскания предупреждение или штраф в соответствии со статьей 11.20.1 Кодекса об административных правонарушениях.**

Статья 11.20.1. Нарушение запретов либо несоблюдение порядка выполнения работ в охранных зонах магистральных трубопроводов (введена Федеральным законом от 12.03.2014 №31-ФЗ).

Совершение в охранных зонах магистральных трубопроводов действий, запрещенных законодательством Российской Федерации либо выполнение в охранных зонах магистральных трубопроводов работ без соответствующего разрешения предприятия трубопроводного транспорта или без его уведомления, влечет наложение административного штрафа на граждан в размере от пятидесяти тысяч до ста тысяч рублей; на должностных лиц – от пятисот тысяч до восьмисот тысяч рублей; на лиц, осуществляющих предпринимательскую деятельность без образования юридического лица, – от пятисот тысяч до восьмисот тысяч рублей или административное приостановление деятельности на срок до девяноста суток; на юридических лиц – от пятисот тысяч до двух миллионов пятисот тысяч рублей или административное приостановление деятельности на срок до девяноста суток.

Перед выполнением работ в охранной зоне нефтепроводов необходимо получить технические условия АО «Транснефть – Прикамье» по адресу: 440043, Республика Татарстан, Казань, ул. Патриса Лумумбы д. 20 корп. 1. Телефоны: **(843) 279-02-90, 279-02-78, 279-04-34;** факс **(843) 279-01-12, 279-04-12.**

В случае обнаружения утечек (выходов) нефти необходимо немедленно сообщить по адресу: 423400, Республика Татарстан, Альметьевск, пр. Строителей, 24; тел. **(8553) 39-62-24; 39-62-32** (диспетчер РДП АРНУ), **39-61-55** (отдел эксплуатации АРНУ).

На правах рекламы

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# Нинди сөт сыйфат таләпләренә җавап бирә

Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе популяр продуктны лаборатор тикшерү нәтиҗәләрен тәкъдим итте.

Моның өчен 30 үрнәк сатып алынган иде. Лаборатор тикшерүләр аларның өчесендә (бу – барлык күләмнең 10 проценты дигән сүз) хилафлыклар барлыгын күрсәтте. Мисал өчен, Ульяновск өлкәсенең «ФОТИДА» җәмгыятендә җитештерелгән «СМК» маркалы сөттә (майлылыгы 3,2 процент, авырлыгы 900 грамм) эчәк таякчыгы төркемендәге бактерияләр таптылар. Эш моның белән генә дә бетми әле: әлеге сөттә микроорганизмнар саны да ($2,8*10^5$ КОЕ/г, норма – $1*10^5$ КОЕ/г) югары.

Балык Бистәсе районының Минфизәр Исмәгыйлев крестьян-фермер хуҗалыгында җитештерелгән «Чишмә» маркалы сөт тә тикшерүне уза алмады. Анысында да эчәк таякчыгы төркеменә кергән бактерияләргә юлыктылар, өстәвенә микроорганизмнар да бик күп булып чыкты.

Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе майлылыгы 3,5-4,2 процент тәшкил иткән «Авылдаш» маркалы пастеризацияләнгән сөттә дә хилафлыклар тапты. Ул Әгерҗе районының Харисов Р.Р. крестьян-фермер хуҗалыгында җитештерелә. Әлеге сөттә дә эчәк таякчыгы төркеменә кергән бактерияләр бар, микроорганизмнар да артыгы белән. Моннан тыш, тикшерелгән барлык үрнәкләр дә «Сөт һәм сөт продукциясенең куркынычсызлыгы турында»гы таможня берлеге техник регламенты таләпләренә җавап бирми.

## Җәүдәт Әхмәтханов:

# «Безнең бурыч – кешеләргә үз хокукларын белергә ярдәм итү»

Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе Җәүдәт Әхмәтханов «Атна вакыйгалары»на кулланучыларның хокукларын яклаудагы үзенчәлекләр хакында сөйләде.

**– Бүген республика кулланучылар базарында нинди вазгыять күзәтелә?**

– Ул бик тиз үсеш кичерә. Кулланучы мөнәсәбәтләре өлкәсендә яңа сегментлар (өлешләп түләү, кулланучы кредитлары, медицина һәм туристлык хезмәтләре), товар сатуның яңа алымнары (шул исәптән, челтәр дистрибьютерлары ярдәмендә, интернет-сатулар һ.б.) барлыкка килә. Бу – кулланучы мөнәсәбәтләрендә һәрвакытта да уңай чагылыш таба дип әйтмәс идем.

**– Әлеге өлкәдә нинди кыенлыклар бар?**

– Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан үткәрелгән эш нәтиҗәләренә анализ ясау күрсәткәнчә, республика кулланучылар базарында, аеруча халыкка сатыла торган товарлар һәм күрсәтелүче хезмәтләрнең сыйфатын һәм иминлеген тәэмин итү өлкәсендә хәл ителмәгән күп кенә проблемалар бар. Кулланучыларның хокукларын бозылуына китергән төп сәбәпләр – халык һәм хуҗалык итүче субъектларның хокукый белеме түбән булу, шулай ук гражданнарның үз хокукларын гамәлгә ашыру механизмнары турында мәгълүматы җитенкерәмәү. Республикада 2013 елның 16 октябрендә Татарстан Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган «2014-2020 елларда Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен һәм җинаятьчелеккә каршы көрәшне тәэмин итү турында»гы Дәүләт программасының кулланучыларның хокукларын яклау буенча «2014-2020 елларда Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклауда комплексы системаны үстерү хакында»гы ярдәмче программа эшли. Аның координаторы – Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясе. Халык арасында актив рәвештә аңлату эшләре алып бару ярдәмче программаның өстенлекле юнәлеше булып тора. Ул кулланучыларның грамоталылык дәрәҗәсен арттырырга һәм үз хокукларын яклау системасын гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирәчәк. Анда кулланучыларның грамоталылыгын күтәрү белән бергә, республика урта уку йортларында кулланучылар белеме нигезләре буенча өстәмә (факультатив) дәресләр һәм олимпиадалар үткәрүгә аерым игътибар бирелә. Моннан тыш, кулланучы базарында хокук бозуларны киметү һәм кулланучыларның дәгъваларын ирекле нигездә хәл итү максатында, хуҗалык итүче субъект вәкилләрен – товар һәм хезмәтләр базарының төрле өлкәләрендә эшчәнлек алып баручы юридик затлар һәм шәхси эшкуарларны укыту белән бәйле юнәлеш өстенлекле алым буларак билгеләнгән.

**– Ярдәмче программа тагын кайсы өлкәләрдә эшли?**

– Аның икенче стратегик юнәлеше – республика кулланучылар базарында тәкъдим ителә торган товарлар һәм хезмәтләрнең сыйфатын арттыруны стимуллаштыру эшчәнлеге. Кулланучыларның барлык таләпләргә туры килә торган продукция сатып алуга хокукларын гамәлгә ашыруда өстәмә гарантияләр бирү, республика кулланучылар базарында сатыла торган куркыныч, сыйфатсыз контрафакт товарларны, шулай ук куллану үзлеге иң яхшы булган продукцияне ачыклау өчен бәйсез экспертизалар, товарлар, эшләр һәм хезмәтләргә чагыштырма тикшерү үткәрергә, шуннан соң кулланучыларны гаммәви мәгълүмат чаралары аша әлеге экспертизаларның нәтиҗәләре белән таныштыру мөһим. Кулланучылар базарының хокук бозулар аеруча еш ачыкланa торган иң проблемалы сегментлары буенча халыкка тарату өчен брошюралар чыгарабыз, матбугатта даими рәвештә мәкаләләр биреп бару да күздә тотыла. Безнең бурыч – Татарстан халкына үз хокукларын яхшырак белергә һәм аларны гамәлгә ашыруда ярдәм итү. Без хокукый культура тормышыбызга үтеп керүен, гражданлык җәмгыятенең аерылгысыз өлеше буларак хокуклар һәм ирекләр турындагы төшенчәнең ныгып урнашуын телибез. Кулланучыларның грамоталылыгын арттыру кешеләрнең үзләре өчен дә, сатучылар, башкаручылар өчен дә файдалы булыр, җәмгыять һәм дәүләт арасында диалог һәм партнерлыкны үстерүгә ярдәм итәр дип өметләнәбез. Сез дә, хөрмәтле укучыларыбыз, читтә калмассыз, редакциягә үзегезне кызыксындырган темаларга сораулар юлларсыз дип ышанабыз. Без аларның берсен дә игътибардан читтә калдырмаячакбыз.

# Сатып алучыны нәрсә саклый?

Төп законнар: «Кулланучыларның хокукларын яклау турында», РФ Гражданлык кодексы. Моннан тыш, кулланучыларның хокукларын РФ Хөкүмәте тарафыннан расланган аерым төр товарлар сату һәм аерым төр хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре җайга сала. Төрле өлкәләрдә хезмәт күрсәтүне көйли торган күпсанлы норматив актлар бар. Мисал өчен, «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында», «Россия Федерациясендә медицина иминиятләштерүе турында», РФ Һава кодексы һ.б.

**Кулланучының сыйфатка, куркынычсызлыкка, мәгълүматка, зыянны кайтаруга карата төп хокуклары:**

**ТОВАРНЫҢ (ЭШ, ХЕЗМӘТ) СЫЙФАТЫ ТҮБӘНДӘГЕ ТАЛӘПЛӘРГӘ ҖАВАП БИРЕРГӘ ТИЕШ**

- килешүгә (әгәр анда сыйфатка бәйле таләпләр булса) туры килүе;
- товарның (эш, хезмәт) билгеле бер максатларга яраклы булуы (әгәр килешүдә сыйфат турында таләпләр булмаса);
- конкрет максатларда куллануга яраклы булуы (килешү төзегәндә сатучыга (башкаручы) әлеге максатлар турында хәбәр ителгән очракта).

**МӘГЪЛҮМАТКА ХОКУК**

Сез таләп итәргә хокуклы:

- җитештерүче (башкаручы, сатучы),
- товар (эш, хезмәтләр),
- эш тәртибе турында мәгълүмат.

Әлеге мәгълүмат

- кирәкле,
- дөрес булырга тиеш.

**КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫККА КАРАТА ХОКУК**

Сез товарны (эш, хезмәт) гадәти шартларда

- куллану,
- саклау,
- ташу,
- утильләштерү вакытында аның
- тормыш,
- сәламәтлек,
- әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудырмавына,
- шулай ук кулланучының милкенә зыян китермәвенә хокуклы.

**ЗЫЯННЫ КАПЛАУГА ХОКУК**

Кулланучының хокукларын бозган өчен (башкаручы, сатучы, вәкаләтле оешма яки шәхси эшкуар, импортер) закон тарафыннан билгеләнгән яки килешүдә каралган җаваплылыкка ия. Әгәр килешүдә закон тарафыннан зур җаваплылык каралган икән, бу очракта килешүдәге шартлар кулланыла.

# АФИША
## 5-11 ИЮНЬ

### Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

**5 июнь** «Воительница-Джырыбына» (П.Ядрихинский)
Олонхо театры (Саха Республикасы, Якутия)
**Башлана:** 19.00
**Билет бәясе:** 150-250 сум
**6 июнь** «Уяну» (С.Сергучева-Баранова)
П.Ойунский исемендәге Саха академия театры
**Башлана:** 19.00
**Билет бәясе:** 150-250 сум
**7 июнь** «Ричард III» (У. Шекспир)
«Дарига-ай» яшьләр театры (Казахстан Республикасы, Сәмәй)
**Башлана:** 11.00
**Билет бәясе:** 250 сум
**7 июнь** «Очам» (З.Попова)
Саха Республикасы дәүләт театры (Якутия)
**Башлана:** 17.00
**Билет бәясе:** 200 сум
**7 июнь** «Җилкәнсезләр» (К.Тинчурин)
**Башлана:** 19.00
**Билет бәясе:** 250-1500 сум
**8 июнь** «Антигона» (Ж.Ануй)
Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театры, Уфа
**Башлана:** 19.00
**Билет бәясе:** 150-250 сум
**9 июнь** «Ай тотылган төндә» (М.Кәрим) Яр Чаллы Татар дәүләт драма театры
**Башлана:** 19.00
**Билет бәясе:** 200 сум
**9 июнь** «Убыр» (А.Кицберг)
«R.A.A.A.M.» эстон театры (Таллин)
**Башлана:** 19.00
**Билет бәясе:** 150-250 сум
**10 июнь** «Ханума» (А.Цагарели)
Кок-Оола исемендәге Тува музыкаль-драма театры
**Башлана:** 18.00
**Билет бәясе:** 150-250 сум
**10 июнь** «Кан-Кыс» (В.Серен-Оол)
**Башлана:** 18.00
**Билет бәясе:** 150-250 сум

### К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

**5 июнь** «Король» (С.Мрожек)
**Башлана:** 17.00
**6 июнь** «Вишневый сад» (А.Чехов)
К.Куанышбаев исемендәге Казах музыкаль-драма театры
**Башлана:** 18.30
**8 июнь** «Качаклар» (Н.Исәнбәт)
Әлмәт Татар дәүләт драма театры
**Башлана:** 18.30
**9 июнь** «Журавли»
Кок-Оола исемендәге Тува музыкаль-драма театры
**Башлана:** 14.00
**11 июнь** «Төш» (Т.Миңнуллин)
**Башлана:** 17.00
**Билет бәясе:** 200-1000 сум

### «ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

**6 июнь** «Бүре җиләге» (Р.Зәйдулла)
**Башлана:** 10.00
**7 июнь** «Кун Эрили»
«Олонхо театры» Саха Республикасының автоном учреждениесе (Якутия)
**Башлана:** 11.00
**8 июнь** «Алтын Әдам»
Казахстан Республикасының Дәүләт курчак театры (Алма-Ата)
**Башлана:** 10.00
**9 июнь** «Сарпике»
Чуваш дәүләт курчак театры (Чабаксар)
**Башлана:** 11.00
**10 июнь** «Красная шапочка» (Ш.Перро)
**Башлана:** 11.00, 13.00
**10 июнь** «Не хочу, не буду!»
**Башлана:** 11.00
**10 июнь** «Теремок» (А.Толстой)
**Башлана:** 11.00, 13.00

### В.АКСЕНОВ СКВЕРЫ
(«МИР» КИНОТЕАТРЫ АРТЫНДА)

**7 июнь** «2+1» (режиссер – Х.Желен)
**Башлана:** 21:00
**Керү ирекле**

### «КРЫЛЬЯ СОВЕТОВ» ПАРКЫ

**7 июнь** «Веселые кеды» гаилә спорт ярышы
**Башлана:** 18.00
**Керү ирекле**

### КАЗАН КРЕМЛЕ

**10 июнь** «Велотөн — 2017»
**Башлана:** 21.00
**Билет бәясе:** 99 сум
(Акчалар ДЦП белән авыручы балаларга тапшырыла)

### «АК БАРС» ЯШЬЛӘР ҮЗӘГЕ

**7,9,10,11 июнь** «Казан каникуллары» Чаллы дельфинариясе гастрольләре
**Башлана:** 11.00, 19.00, 15.00
(10,11 июнь көннәрендә)

### «ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

Язучы Марсель Галиевнең «ТЫНЛЫК ДӘШКӘНДӘ» дип аталган фотокүргәзмәсе
**Керү ирекле** (эш көннәрендә).

5+

# «Без стартка әзер»

**10 июнь көнне Казанда «Гонка героев. Новая высота» – каршылыклы дистанция буенча йөгерү ярышлары уза. Биредә республиканың яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов та улы белән катнашачак.**

Биредә йөгереп кенә калмыйсың. Ун чакрымга сузылган дистанциядә 23 каршылык. Казанлылар мондый төр ярышларда үзләрен моннан ике ел элек сынап караган иде. Ул вакытта ярышлар танк училищесы хәрби полигонында үтте. Быел ул бөтенләй яңа форматта. Беренчедән, урыны башка – Зөя тау чаңгысы шуу комплексында узачак. Андагы ландшафт әлеге төр ярышлар өчен кулай.

– Август аенда шушы ук урында геройлар чабышының Россиякүләм ярышларына сайлап алу этабын оештырабыз. Бу – үзеңне сынап карау өчен менә дигән мөмкинлек, – ди оештыручыларның берсе Кирилл Воробьев.

Каршылыкларның барысын да үтү мәҗбүри түгел, кеше үз көчен чамаларга тиеш. Ләкин финишка бер кеше дә коры килмәячәк. Берәр каршылыкны үтә алмасаң, сазга яки суга килеп төшәсең. Хәер, адреналин артыннан куучыларга бу артык куркыныч әйбер түгел. Финишта аларны кайнар душ һәм чиста киемнәр көтеп тора.

Элек стартка бары тик ун кешелек командалар гына баса алса, хәзер андый таләп юк. Кеше ялгызы да дистанциягә үтә ала.

Владимир Леонов та ярышларның әзерлек дәрәҗәсен ошаткан. Мондый ярышны ул күптән күзләп йөргән.

– Бу көнне ашыгыч эшләр булмаса, мин улым белән ярышта катнашырга уйлыйм. Без стартка әзер. Аның белән еш йөзәбез, йөгерәбез. Ике дустым да араны хатыннары белән узачак. Безнең командада 10 кеше булачак, –ди Владимир Леонов.

## Конфедерация Кубогы алдыннан – ялга

Россиянең футбол җыелмасы Конфедерация Кубогына кайда әзерләнә дип уйлыйсыз? Футболчылар Австриянең Альп тауларында ял итә. Тренировкалары исә Нойштифт тау курортында уза. Мондагы һава, тынычлык, табигать спортчыларга уенга ныклап әзерләнергә ярдәм итә, ди тренерлар. Футболчылар шәһәр читендәге Jagdhof дип аталган биш йолдызлы кунакханәдә яши. Команда 70 бүлмәнең 50сен арендага алган.

Сүз уңаеннан, ил җыелмасының беренче матчы 17 июнь көнне Яңа Зеландия командасы белән була. Уен Санкт-Петербург стадионында узачак. Казандагы беренче матч 18 июньдә Португалия – Мексика арасында уза.

**Казанның «Рубин» футбол клубының яңа президенты итеп Радик Шәймиев сайланды. Казан мэры Илсур Метшин исә клуб президенты вазифасын калдырды. Хәзер идарә һәм финанс мәсьәләләре тулысынча «ТАИФ» компанияләре карамагына күчәчәк.**

# Шәймиев улы «Рубин»ны җитәкли

52 яшьлек Радик Шәймиев – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең кече улы. Үз даирәсендә Шәймиев улын көчле куллы, акыллы, катгый эшмәкәр буларак беләләр. Спортта да чит кеше түгел ул. Радик Шәймиев безгә оста көрәшче, автоузышчы буларак та таныш. Тикмәгә генә Чехиядәге бер автостраданың борылышын «Шәймиевләр борылышы» димиләр инде.

Аның эшмәкәрлек тәҗрибәсе «Рубин»ның финанс мәсьәләсен дә хәл итәр дип фаразлыйлар. Узган ел команда ун яңа уенчы алу өчен генә дә 40 миллион евро акча туздырган иде. Ләкин Россия чемпионатында тугызынчы урын алып, «Рубин» өметне дә, чыгымнарны да акламады. Хәзер клубка тренер эзлиләр. Кайбер фаразлар буенча, «Рубин»ны янәдән Корбан Бердыев җитәкләячәк.

Шәһри КАЗАН
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1580. Гомуми тираж – 5955.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 720. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы